**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_26__» ___04___ 2023 ел** **№ ___100___**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 18 октябрендәге 259 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибе» карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2022 елның 30 сентябрендәге 288 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 4 февралендәге 110 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарын үтәү йөзеннән Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 18 октябрендәге 259 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибе» карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә (2022 елның 30 сентябрендәге 288 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Компенсация ата-анага (законлы вәкилгә) билгеләнә һәм түләнә, гаиләсенең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы "Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында" карары нигезендә билгеләнгән, ул мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияли, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә (алга таба - мөрәҗәгать итүче).».

1.2. 2.3. пунктта «компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айдан соңгы алты айда» сүзләрен «гариза биргән ай алдыннан соңгы 12 календарь айда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет-телекоммуникация челтәренең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов